ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Янгын куркынычсызлыгы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) беренче өлештә “янгыннарга каршы көрәшкә” сүзләрен “янгыннарны кисәтүгә, аларны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга” сүзләренә алмаштырырга;
б) өченче өлештә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:
“13) янгыннарны кисәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру.”;

2) 4 статьяның җиденче абзацында “янгыннарга каршы көрәштә” сүзләрен “янгыннарны кисәтүдә һәм аларга каршы көрәштә” сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:
“Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итүне оештыру һәм янгыннан саклану эшчәнлеген координацияләү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

4) 19 статьяда:
а) җиденче өлештә:
беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Янгыннан саклану бүлекчәләренең көчләре, җәлеп ителгән көчләр һәм бердәм дәүләт гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү системасы чаралары белән янгыннарны сүндергәндә һәм һәлакәттән коткару эшләрен гамәлгә ашырганда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, мөлкәтне коткару буенча, шул исәптән түбәндәге кирәкле гамәлләр башкарыла:”;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“янгыннарның куркыныч факторлары, һәлакәтләрнең куркыныч чагылышлары йогынтысындагы зоналарда булган оешмалар хезмәткәрләренең һәм аларның территорияләрендәге башка гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян килү куркынычы булса, әлеге оешмаларның эшчәнлеген туктатып тору.”;

б) унынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Янгын сүндерү җитәкчесе янгын зонасын билгели, янгын сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару гамәлләре үткәрелә торган территория чикләрен, күрсәтелгән гамәлләрне башкару тәртибен һәм үзенчәлекләрен билгели, кешеләрне һәм мөлкәтне коткару, кирәк булганда, янгынны сүндерүгә өстәмә көчләрне һәм чараларны, шул исәптән бердәм дәүләт гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү системасы чараларын җәлеп итү турында карар кабул итә, янгын урынында янгыннан саклану бүлекчәләренең һәм янгын сүндерүгә җәлеп ителгән көчләрнең гамәлләре белән идарә итү тәртибен билгели, янгын урынында килүче көчләрне һәм чараларны урнаштыра, янгын зонасында янгын сүндерүдә катнашучылар һәм янгын сүндерүгә, һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга җәлеп ителгән көчләр белән элемтәне оештыра, алга таба янгын чыгу сәбәбен билгеләү өчен янгын урынында әйберләр рәвешендәге дәлилләрне, мөлкәтне һәм әйберләрнең урнашу тәртибен саклау чараларын күрә. Кирәк очракта янгын сүндерү җитәкчесе башка карарлар, шул исәптән күрсәтелгән территориядә вазыйфаи затларның һәм гражданнарның хокукларын чикли торган карарлар да кабул итә.”;

5) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“22 статья. **Янгынга каршы пропаганда һәм янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү**

Янгынга каршы пропаганда массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус әдәбият һәм реклама продукциясе бастыру һәм тарату, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр ярдәмендә һәм халыкка мәгълүмат бирүнең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка рәвешләреннән файдаланып гамәлгә ашырыла. Янгынга каршы пропаганданы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле органы, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар үткәрә.

Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү янгынга каршы инструктаж һәм (яисә) янгын-техник минимумы программалары буенча башкарыла.

Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук һөнәри белем бирү программалары эчтәлегенә

карата таләпләр, программаларны раслау һәм килештерү тәртибе федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

Гамәлгә ашырыла торган программа төренә карап, оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү турыдан-туры эш урынында һәм (яисә) мәгариф эшчәнлеген башкаручы оешмаларда үткәрелә.

Мәгариф оешмаларында белем алучыларны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү мәҗбүри үткәрелә. Мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы органнар һәм янгыннан саклану хезмәте ирекле яшь янгын сүндерүчеләр дружиналары төзергә мөмкин. Ирекле яшь янгын сүндерүчеләр дружиналары төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 18-ТРЗ